| СОВЕТ<br>КУРКУЛЬСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>КЫРКҮЛ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.08.2024 № 75

с. Куркуль

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кыркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 15.08.2023 ел, №52 Совет карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кыркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кыркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 5 августындагы карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыркүл авыл җирлеге Советы

**карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркүл авыл җирлеге Советының 15.08.2023 ел, № 74 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркүл авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- **7 статьяны** түбәндәге эчтәлектәге яңа абзац белән тулыландырырга:
«**юл сервисы объектлары** - юл хәрәкәтендә катнашучыларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән биналар, корылмалар, төзелмәләр, башка объектлар (автозаправка станцияләре, автостанцияләр, автовокзаллар, кунакханәләр, кемпинглар, мотельләр, җәмәгать туклануы пунктлары, техник хезмәт күрсәтү станцияләре, шуңа охшаш объектлар, шулай ук аларның эшләве өчен кирәкле ял итү урыннары һәм транспорт чаралары тукталышлары);»;
- **8 статьяга** түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт өстәргә:
«3.1. Автомобиль юлларының юл яны полосасында яки аларга якын урнашкан сервис объектлары (кибетләр, кафелар, кунакханәләр, АЗСлар, ТХС, ял итү

мәйданчыклары) өчен бүлеп бирелгән территорияләрне тоту һәм җыештыру мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан башкарыла.»;

-түбәндәге эчтәлектәге **4.1 бүлеге** белән тулыландырырга:

**«4.1 нче бүлек. «Сервис объектларын карап тоту.**

**15.1 нче статья**

1.Сервисның территориаль объектларын тоту мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан башкарыла.

2. Сервис объектларын һәм аларга якын территорияләрне урнаштыру һәм карап тоту таләпләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Кыркүл авыл җирлеге**
**Советы утырышында**
**рәислек итүче, 4 нче сайлау**
**округы депутаты** **А.А.Косов**